ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш, Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш., Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№213 от «05» 06 2020 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
2018 нче елның 6 нчы июнендә кабул
ителгән 370 нче номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә, хезмәт күрсәтүчеләргә субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында " 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының социаль-әһәмиятле темаларын, муниципаль проектларын массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуга юнәлдерелгән чаралар буенча чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 нче елның 6 нчы июнендә кабул ителгән 370 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының социаль әһәмияткә ия булган темаларны, муниципаль проектларын массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуга юнәлдерелгән чаралар буенча чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- субсидияләр алучылар-юридик затлар үзгәртеп кору, бетерү процессында булырга тиеш түгел, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә субсидия алучылар-шәхси эшмәкәрлек эшчәнлеген индивидуаль эшкуар буларак туктатмаска тиеш;1.2. 2.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2.4.1 пунктчасы өстәргә:

0000010492

Субсидияләр бирү шартларын һәм тәртибен билгеләгәндә түбәндәге мәгълүмат күрсәтелә:

- субсидияне баш идарәче кабул иткәннән соң бюджет акчаларын алучы буларак ун эш көненнән дә соңга калмыйча күчерү турында документларны карау нәтиҗәләре буенча;

- Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында субсидия алучыларга ачыкланган исәп-хисап яки корреспондент счетларына субсидияләр күчерү турында;

- субсидия бирелә торган чыгымнар (алынмаган керемнәр) юнәлешләре турында;

- фактта җитештерелгән чыгымнарны (алынмаган керемнәр) раслый торган документлар исемлеге турында, шулай ук кирәк булганда, мондый документларга карата таләпләр турында.

1.3. 1 кушымтаның 2.9 пунктының 1 абзацын түбәндәге редакциядә:

Субсидия бирү турында Карар кабул ителгән очракта, Башкарма комитет мөрәҗәгать итүче белән 2 нче кушымтаның типлаштырылган формасы нигезендә килешү төзи, ул субсидия күчерү өчен нигез булып тора.

1.4. 2 нче кушымтаның 2.1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Субсидияләр биргән бюджет акчаларын баш бүлүче (бүлүче) һәм дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүе органнары тарафыннан субсидияләр бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруга ризалык бирә.

1.5. 2.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2.8.1 пунктчасы өстәргә:

Субсидия алудан баш тарту өчен нигезләр:

субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.7 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә бирмәү);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының матбугат һәм массакүләм чаралары белән хезмәттәшлек секторына әлеге карарны интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов